Сайт школы:
http://kazan33.ru

# Школа радости

Издается
с 2009 года

№5 (115) 2020

• ГАЗЕТА ГИМНАЗИИ №33 АВИАСТРОИТЕЛЬНОГО РАЙОНА г. КАЗАНИ •

## 75 ҖИҢҮ!
1945–2020

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Сугыш... Иң куркыныч сүзләрнең берседер бу, мөгаен. Икенче Бөтендөнья сугышы кагылмаган, шул афәт ишеген какмаган бер генә гаилә дә юктыр. Миллионлаган кешеләрнең бала чагын, яшьлеген урлаган, күпме сабыйны ятим иткән, тигез гаиләдә яшәүдән мәхрүм калдырган кара еллар...

Татарстаннан да 700 меңнән артык кеше яу кырына киткән. Шуларның һәр икесенең берсе ятып калган. Бик зур авырлыклар белән бирелгән ул Җиңү безгә. Зур сынаулар, күп югалтулар, авыр юллар аша...

Без, хәзерге буын яшьләре, чын ветераннарны үз күзләребез белән күреп тә белмибез инде. Әбиләребез, бабайларыбыз, әти-әниләребез сөйләве буенча гына беләбез. Инде ветераннар бик аз калган. Шулай булса да, без аларны онытырга тиеш түгел, хакыбыз юк. Бүгенге аяз күгебез, матур яшәвебез белән без аларга бурычлы! Мәңгелек Дан аларга!

**Динара ПЕТРОВА, 9 «Л»**




*9 «В» сыйныф укучысы* ***ФАТТАХОВА Альмираның*** *рәсеме*

## БУ САНДА УКЫГЫЗ:

2 бит СУГЫШТА БУЛГАН БАБАМ
3 бит БЕЗ АЛАРГА ҺӘРЧАК БУРЫЧЛЫ
4 бит МӘҢГЕЛЕК ДАН АЛАРГА!
5 бит БАБАМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ!
6 бит СУГЫШТА БЕЗНЕҢ ГАИЛӘ ТАРИХЫ
7 бит «АТ ҖЕНЕ КАГЫЛГАН» МӘҖИТ БАБАМ
8 бит ИҖАТ ДУЛКЫНЫНДА



*Бабамның*
*истәлегенә*
*багышлыйм бу*
*юлларны,*
*Имин тормыш*
*бүләк иткән,*
*җиңеп*
*юлбасарларны!*
***75 ел*** *саклыйбыз без аяз күк,*
*алсу таңны.*
*Искә алып җырлыйбыз без,*
*Җиңү китергән язны!*

***Нәфисә ЗАКИРОВА,***
***4 «А»***

# СУГЫШТА БУЛГАН БАБАМ



Сугыш – ул бик куркыныч сүз... Ләкин ул бик күп язмышларны, шәһәрләрне, авылларны һәм гади кешеләрне берләштергән. Тыныч яшәгән кешеләр минут эчендә пуля һәм атака астында калган. Алар соңгы тамчы канына кадәр үз иленең намусы һәм якты киләчәге өчен көрәшкән.

Минем бабам да хәрби бәрелешләрдә катнашкан. **Закиров Гыйльфан Гыйльман улы** 1924нче елның 1нче гыйнварында ТАССР-ның Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында туган. 1942нче елда, 18 яшендә, Кызыл Армия сафларына алына. Төньяк-Көнбатыш фронтта 5нче укчы дивизиясенең 336нчы укчы полкында рядовойлар булып сугышка керә. Гжатск, Сума, Казатин өчен көрәшләрдә катнаша. Сугышларның берсендә башы авыр яралана һәм бабай Ашхабад шәһәре госпиталенә дәвалануга күчерелә. 1944нче елда дәваланганнан соң, комиссиягә алына һәм туган авылына демобилизацияләнә. «I дәрәҗә Ватан сугышы «ордены», «1941-1946нчы елларда Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән. Сугыштан соң Балык Бистәсе районы Корноухово совхозының ашлык кабул итү пункты белән житәкчелек иткән. Өйләнгән һәм 7 бала тәрбияләп үстергән. 2004нче елда вафат булган.

Мин Гыйлфан бабам белән чиксез горурланам, чөнки ул Бөек Җиңүгә өлеш керткән һәм безгә тыныч күк бүләк иткән.

**Инзилә ШАКИРОВА, 11 «Г»**



Минем бабам **Хаялов Акмал Хәялетдин улы** 1910нчы елның 4нче февралендә Апас районы Карамасар авылында туган.

1941нче елның 6нчы июлендә аны сугышка алалар. Бабам Ленинград өлкәсендә 951нче атучылар полкында сугышка керә. Ике айдан ул хезмәт иткән полк чолганышка эләгә, аны тоткынлыкка алалар. Ул Финляндиядә өч ел әсирлектә була. 1944нче елның октябрь аенда аларны азат итәлә.

Минем бабай Җиңүне Украинада каршылый. Туган авылына 1946-нчы елның июнь аенда гына әйләнеп кайта.

Сугыштан соң бабам үз туган авылында яши, механизатор булып эшли. Әбием белән алар дүрт малай тәрбияләп үстерәләр. Бабам 1996нчы елның 26нчы июнендә 86 яшендә вафат була.

Бабам һәм аның белән бәйле истәлекләрне без кадерләп саклыйбыз. Сугыш беткәнгә 75 ел вакыт узса да, аның ачы яралары, бабайларның батырлыгы мәңге онытылмас.

**Булат ХАЯЛОВ, 7 «А»**



Минем бабам **Тимершин Галиәхмәт Тимерша улы** 1898нче елның 11нче февралендә туган. Бабам 1918нче елгы Гражданнар сугышында катнашкан.


1941нче елда ул Бөек Ватан сугышына Яшел Үзән районының Айдар авылыннан киткән. Сугыш аның өчен Мәскәү өлкәсе Можайск шәһәреннән башланган. Алар анда 220 километрга сузылган оборона линиясе төзегәннәр. Бабам сугышта 5нче армия составында көрәшкән.

1942нче елгы сугышлар барышында бабам каты яраланып, хәрби госпитальгә эләккән. Анда дәваланганнан соң, ул хезмәткә – сугышка яраксыз дип табылган. 1943нче елда бабам туган якларына әйләнеп кайткан.

Сугыш чорында ат җигеп эшләгән. Атка төяп икмәк ташыганнар, фронтка ашлык озатканнар. Бабам сугыштан соң да гомер буе авылда эшләгән. 1979нчы елда 81 яшендә бабам вафат булган.

Мин үземнең бабам белән бик горурланам! Сугыш ветераннарына без бик тә рәхмәтле!

**Камил ТИМЕРШИН, 5 «А»**



# БЕЗ АЛАРГА ҺӘРЧАК БУРЫЧЛЫ!



Минем бабам **Шәрәпов Кәшәфетдин Шәрәфетдин улы** 1920-нче елны Кама Тамагы районы Даныш авылында дөньяга килә. 1939нчы елда 18 яшендә армия сафларына алына. Ләкин аңа армиядә хезмәт итеп кайтырга насыйп булмый. Дәүләт алдындагы бурычын үтәп, инде туган җирләренә кайтам дип йөргән мәлдә, II Бөтендөнья сугышы башлана. Бабамны сугыш башланган көннән үк фронтка җибәрәләр. Ул 114нче укчылар дивизиясенең 536нчы укчылар полкында кече сержант булып хезмәт итә.

Сугыш вакытында беркемгә дә җиңел булмый: яраланып госпитальдә яткан чаклар да була. Кызганыч, бабам туган якларына исән-сау кайта алмый. Сугыш бетәргә бер ел чамасы калгач, 1944нче елның 22нче июнендә Сверь елгасын кичкән чакта аларның көймәләре фашист самолетлары тарафыннан бомбага тотыла. Шул мизгелдә бабамның гомере өзелә. Бабам Ленинград өлкәсе Киров тимер юлында Шамокша разъездында җирләнгән. Безгә истәлек булып, бабамның бер-ике сурәте генә калган.

Мин бабамның батырлыгы, безгә матур тормыш, аяз күк йөзе, тыныч тормыш бүләк итүе белән чиксез горурланам.

Кызганычка каршы, ветераннарыбызның саны елдан-ел кими. Киләчәк буыннарга күрсәтерлек әби-бабайларыбыз бетеп бара. Шуңа күрә булган мөмкинлекнең кадерен белеп, ветераннарыбызга хөрмәт күрсәтеп яшик!

**Зәринә ИСМӘГЫЙЛОВА, 10 «Э»**



Минем бабам **Фазылҗанов Фосыфҗан Фазылҗан улы** хәзерге Әтнә районы (элек Арча районына караган) Дусым авылында гади крестьян гаиләсендә туган. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа бары 18 яшь булган. Шул ук җәйдә аны сугышка алып киткәннәр. Ул 1941нче елның җәеннән 1943 нче елның көзенә кадәр көрәшкән. Ике тапкыр яраланган. Беренче тапкыр, кулына пуля тиеп, госпитальдә дәвалангач, кабат сугыш кырына әйләнеп кайткан. Икенче тапкыр пуля аягына тиеп, балтыр сөяген ватып, аягын тишеп чыккан. Озак дәваланганнан соң, аны сугыштан өенә кайтарып җибәргәннәр.

Әнием кечкенә вакытта, дәү әти аларга пуля эзен күрсәтеп, сугышта үзенең ничек яраланганы турында сөйли торган булган. Кызганыч, мин ул бабам турында әни сөйләгәннәрдән генә беләм. Мин туганчы ул инде вафат булган. Авылдагы өйдә бабамның орден-медальләре әле дә саклана.

Сугыштан соң бабай гомере буе комбайнда эшләгән. Тыныч тормышта да илне күтәрүгә, халыкның тормышын яхшыртуга үзенән зур өлеш керткән.

Сугыш тәмамлануга 75 ел вакыт узса да, илебез азатлыгы өчен үзләреннән зур өлеш керткән әби-бабаларыбызны без онытырга тиеш түгел. Батырларның даны мәңгелек! Тыныч тормышта яшәвебез белән без аларга һәрчак бурычлы!

**Данил ПЕТРОВ, 4 «А»**



Минем бабамның исеме – **Хәсәнов Хәйдәр Хәсән улы.** Ул 1915нче елда Балык Бистәсе районы Яңа Ырга авылында туган. Бабам 1941нче елда 26 яшендә сугышка киткән. Ул анда разведчик булып хезмәт иткән, сугышның иң алгы сызыгында көрәшкән. Фашистларны җиңеп, туган якларына исән-сау кайткан.

Минем бабам бик күп медальләр һәм Бөек Ватан Сугышы ордены белән бүләкләнгән. Сугыштан кайткач, гомер буе авылда колхозда бригадир булып эшләгән. Бабам 2003нче елда 88 яшендә вафат булган.

Хәзер әбием ялгыз яши, бик еш кына бабамны сагынып искә ала, безгә аның турында төрле истәлекләр сөйли. Сугыш тәмамлануга 75 ел вакыт узса да, сугыш кешеләр күңелендә онытылмый. Без дә бергәләп бабамның әбиемә сугыштан язган хатларын укыйбыз, аның орден-медальләрен карыйбыз, бабамның батырлыгына сокланабыз. Мин шундый батыр бабамның оныгы булуым белән чиксез горурланам!

**Гадел ШӘФЫЙГУЛЛИН, 7 «А»**

# МӘҢГЕЛЕК ДАН АЛАРГА!



Минем әниемнең бабасы – **Сафин Гыйлемҗан Гыйлемхан улы** Бөек Ватан сугышында катнашкан. Ул Ленинград блокадасы чолганышында илебез өчен явыз немец дошманнарына каршы көрәшкән.

Бабам 1942нче елның 15нче августында 17 яшьлек яшүсмер вакытта Кызыл Армия сафларына алына. 6 айлык сугышчан әзерлекләрдән сон бабамны фронтка җибәрәләр. Ул 46нчы укчы дивизиянен 47нче автотранспорт ротасында атучы булып хезмәт итә.

1944нче елнын 15нче июлендә бабамның сул кулы нык яралана, ул контузия ала. Озак вакыт госпитальдә ята.

Бабам бик күп хөкүмәт бүләкләренә, медальләргә ия. «Батырлык өчен», «Ленинград оборонасы өчен» орденнары белән бүләкләнгән. Кызганычка каршы, күп орден-медальләре бүгенге көнгә кадәр сакланмаган.

2016нчы елга кадәр бабаем Балык Бистәсе районында хуҗалык алып барган. Бик озак еллар колхозда эшләгән. Аны район башлыклары, мәктәп дирекциясе төрле чараларга, очрашуларга чакырып тора иде. Бабам турында мәктәп укучылары, укытучылар, туган якны өйрәнү музее хезмәткәрләре шактый мәгълүмат туплаганнар.

Безнен гаилә бабам белән бик горурлана! Сугышта катнашып, Җину бүләк итүе өчен без анын алдында баш иябез!

**Әмир САДЫЙКОВ, 5 «А»**



Бабам **Хәбибуллин Зиннәт Хәбибулла улы** 1908нче елда Кукмара районының Ядегәр авылында туа. Балалык елларында илдә булган ачлыкны үз җилкәсендә татый. Вакытыннан алда өлгерергә, хезмәт юлына басарга туры килә аңа. Сугыш башланганчы ул Шәмәрдән бистәсенең мех фабрикасында эшли.

1941нче елда, Бөек Ватан сугышы башлангач, бабам фронтка 33 яшендә китә. Сугыш башланганда аны Мари урманнарына озаталар. Уку-өйрәнү лагерыннан соң бабамны фронтка җибәрәләр. Сугыш вакытында ул интендант гаскәрләрендә хезмәт итә. Аннан тыш, ул әле тегү эше белән дә шөгыльләнә. Сугышнын башыннан ахырына кадәр күпме юл үтә ул?! Берлинга кадәр барып җиткән бит Кукмара районында үскән гади татар солдаты!!!

Ул 1945нче елда ефрейтор дәрәҗәсендә сугыштан туган якларына әйләнеп кайта. Сугыштан соң ул мех фабрикасында эшләвен дәвам итә. 1976нчы елда вафат була.

**Талия ХӘЙРУЛЛИНА, 5 «А»**



Минем бабам – **Нәҗипов Гомәр Нәҗип улы** 1909нчы елның 9нчы маенда Апас районының Кулларово авылында күп балалы гаиләдә туган. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941нче елның июнендә хәрби училищега укырга керә. 1942нче елның февралендә 117нче укчы дивизиясе составында фронтка җибәрелә. Башта ул дивизиянең политругы, ә 1944нче елда командир итеп билгеләнә. Бабам Кенингсберг һәм Берлин өчен барган иң авыр сугышларда катнашкан. Калинин, Белорусс, Украин фронтларында сугышкан. Өч тапкыр «Бөек Ватан сугышы», «Кызыл йолдыз», «Александр Невский» орденнарына лаек булган. Аңа Берлинны алган өчен, Кенингсбергны алган өчен һәм Алманияне җиңгән өчен медальләр бирелгән.

Берлинны алганнан соң, бабамны Чехословакиягә җибәргәннәр. Ул Казанга бары тик 1946нчы елны гына кайткан. Күп еллар автотранспорт хуҗалыгында кадрлар бүлеге җитәкчесе булып эшләгән. 1970нче елда пенсиягә киткән. 1983нче елда вафат булган.

**Самат НӘҖИПОВ, 5 «А»**

# БАБАМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ



Минем карт бабаемның исеме – **Гыйльметдинов Габдрахман.** Ул 1918нче елның 25нче декабрендә Биектау районы Ямаширмә авылында туган.

Габдрахман бабай Бөек Ватан сугышының беренче көненнән алып, соңгы көненә кадәр сугышта катнашкан. Аны 1928нче елның октябрендә армия сафларына алалар. Ул Минск шәһәрендә хәрби училище тәмамлап, лейтенант дәрәҗәсенә ирешә.

Сугыш башлангач, Белоруссия фронтында сугыша. 1943нче елда карт бабай фашистларга әсирлеккә төшә. Бәхеткә каршы, атарга алып барган җирдән ул качып котыла. Сугыш барышында бернечә тапкыр яралана.

Сугыш беткәч, бабай туган якларына исән-сау әйләнеп кайта. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен бик күп орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Алар арасында «Батырлык өчен!» медале, «I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены» кебек зур дәрәҗәле бүләкләр бар.

Минем карт әбием белән алар ике малай, бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Ул кыз – минем дәү әнием.

Кызганычка каршы, карт бабаем исән түгел инде. Ул 2003нче елның гыйнварында вафат булган. Минем әбием һәм әниемнен сөйләүләре буенча, минем бабам сугыш елларын һәм сугыштагы иптәшләрен бик еш искә алган. Мин карт бабам белән бик горурланам!

**Газиз ЗАКИРҖАНОВ, 5 «А»**


---

Сүзем гади генә, матур табигатьле, Буа районына кергән, Казма авылында туып үскән һәм шунда гомер кичергән дәү этием, **Абзалов Шәрип Абзалетдин улы** турында. Әйе, мин дәү этиемне бөек шәхес итеп күрәм һәм, әлбәттә, горурланам.

Дәү этием 1910нчы елның 12нче августында Буа өязе Черки Кощаково авылында крестьян гаиләсендә туа. Җиде балалы гаиләдә иң төпчек бала була. Әти-әниләре җир кешеләре, җир хезмәтен башкаралар. Бик ярлы яшиләр, ачлыктан интегәләр. 1921нче елгы ачлык вакытында бабам 11 яшьлек малай була. Гаилә ишле, ашарга юк. Бәхеткә каршы, гаилә бу авыр елларда исән кала. 4нче классны бетергәннән соң, бабам тракторчы һөнәрен үзләштерә. 1928нче елда Кызыл Армия сафларына алына. Армия хезмәтен үтәп, туган авылына кайта һәм тракторчы булып эшли башлый. Ул төпле, тырыш егет була, шуңа күрә дә аңа тракторны ышанып тапшыралар. Бабам Шәрип Абзалетдин улы 1939нчы елда күрше авыл кызы *Хөсәенова Зәйнәп Харис кызына* өйләнә. Аларның сугышка кадәр бер ул һәм бер кызлары туа.

1941нче елның 22нче июнендә бөтен совет кешесе өчен тыныч тормыш бетә. Җәй... Эссе... Бөтен халык кыр эшендә. Колхозда уңыш җыя торган вакыт. Уңыш җыеп бетергәнче дип кенә авыл ирләрен фронтка җибәрми торалар. Октябрь аенда эш бераз кимегәч, халык фронтка китә. Бабамны ул елны фронтка алмыйлар, чөнки колхозда эшләргә дә кешеләр кирәк була.

1943нче елны бабам үзе теләп фронтка китә. 1943нче елның 11нче февраленнән 1945нче елның 9нчы маена кадәр бабам 916нчы номерлы атучылар полкының составында, Волхов һәм өченче Балтыйк буе фронтының 1080нче номерлы стрелковый полкы составында танкист-пулеметчик була. 1943нче елның август аенда бабамның җилкә һәм аягына пуля тия, ул яралана. 1944нче елның июнь аенда аны контузиялиләр. Яшь, көчле, эшләп чыныккан организм тернәкләнә, дәү этием исән кала. 1945нче елның 9нчы мае Җиңү көнен күрергә насыйп була аңа да. 1945нче елның 25нче сентяберендә Югары Совет президиумы указы белән Шәрип Абзалов демобилизацияләнә.



1946нчы елда ул туган авылына әйләнеп кайта. Сугыштан соң колхозда эшли, тракторчы, моторист була, тегермәндә, амбарда, электростанциядә эшли.

Сугыштан соң тагын дүрт баласы туа. Бабам 83 яшендә 1993нче елның 19нчы июнендә бу дөньядан китә.

**Рүзәл ГЫЙНИЯТУЛЛИН, 7 «А»**

# СУГЫШТА БЕЗНЕҢ ГАИЛӘ ТАРИХЫ



Валеев Закир Абдуллович

Минем бабам **Вәлиев Закир Абдулла улы** (әниемнең бабасы) 1916нчы елның 21нче октябрендә туа. Аны 1941нче елның 27нче июлендә Чуаш АССРы, Козловка районы, Әлмән авылыннан сугышка алалар. Украина фронтының 1нче аерым укчылар батальонының 2нче танк бригадасында (64 тбр 1УкрФ) хәрби шофер булып хезмәт итә. Харьков өлкәсенең Ивоправка авылын яулап алганнан соң, мина шартлавыннан аяк сөяге авыр яралана. Госпитальдә озак дәваланганнан соң, аңа 3нче группа инвалид дәрәҗәсе бирелә.

Туган авылына кайткач, колхозда бригадир булып эшли. 1947нче елда әбием Оркыяга өйләнә, аларның өч уллары һәм бер кызлары туа. Әби белән бабай 50 ел бәхеттә, тигезлектә гомер кичерәләр. Төпчек уллары Хәйдәр – минем дәү әтием.

Закир бабай 2нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм 3нче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнгән.

Ул 1997нче елның 28нче сентябрендә вафат була. Мин үземнең бабам белән бик горурланам!

*(Бу хакта әнинең әбисе Әлфия Закирова сөйләде)*

**Вәлиев Хәкимулла Вәли улы** хатыны Мәсерура белән Чуаш АССРынның, Козловка районы, Әлмән авылында матур гына гомер итәләр, тыныч кына яшиләр.

Бөек Ватан сугышы башланганнан соң, бабай 46 яшендә йөкле хатынын һәм биш баласын калдырып, фронтка китә. Олы улы Рәхимуллага – 14, Нурдидәгә – 13, Әлфия әбигә – 11, Халидәгә – 8, кече кызына 3 яшь була ул чакта, ә әби тагын кечкенә сабый көтә. Барлык ир-атлар сугышта, ә авылда балалар һәм хатын-кызлар гына кала. Алар никадәр генә авыр булса да, бер-берләренә булышып яшиләр, соңгы сынык икмәкләрен бүлешәләр... Балалар әниләренә хуҗалыкта булыша, калган яшелчәләр, үләннәрне бакчаларда, басуларда җыеп, ачтан үлмәс өчен, тамакларын туйдырып йөриләр. Бераз он алу өчен, авылда калган картлар белән күршедә 5 чакрым ераклыкта урнашкан авылга арба тартып, тегермәнгә йөриләр.

Хакимулла бабай 1941нче елның көзеннән 1942нче елның язына кадәр Мәскәү оборонасында катнаша.

1942нче елның гыйнварында Мәсерурә әби малай таба, аңа Галимулла исеме кушалар.



Валеев Хакимулла Валеевич

Әби хәтирәләре буенча, 1942нче елның мартында бабай өенә бер төнгә кайта. Ул үзенең яңа туган улын, балаларын күреп, гаиләсе белән саубулашып янадан фронтка китә. Бу аларның соңгы тапкыр очрашуы була.

1942нче елның 26нчы ноябрендә Хәкимулла Вәли улы Тверь өлкәсенең Кувшиново авылындагы эвакуация госпиталендә яраларыннан үлә. 1942нче елның 2нче декабрендә Кувшино авылы янында туганнар каберлегендә җирләнә.



Закиров Хазиб Закирович

Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, тормыш җайга салына башлый. 1954нче елда минем әбием Әлфия **Закиров Хажиб Закир улына** кияүгә чыга һәм 1955нче елда минем дәү әнием Гүзәл туа. Хажиб бабай сугыш вакытында Казанда 144нче заводта фронт өчен хезмәт куя. 9нчы майны төнге сменадан эштән чыккач Бауман урамында бөтен шәһәр халкы белән Җиңү таңын каршы ала.

Без гаиләбез белән, бабаларыбыз турындагы хәтирәләрне кадерләп саклыйбыз, ел саен геройларыбызның фоторәсемнәрен Үлемсез полкка алып барабыз.

**Алинә МИНҺАҖЕВА, 7 «Г»**

# «АТ ҖЕНЕ КАГЫЛГАН» МӘҖИТ БАБАМ





Минем карт бабаем **Гарипов Мәҗит Гариф улы** 1920нче елның 24нче гыйнварында Татар Тау Иле авылында туа. Ул кечкенәдән үк авыл егетләре белән сукага чыга, 17 яшендә колхоз идарәсе аны бригадир итеп куя.

1941нче елның 18 апрелендә Кызыл Армия сафларына алына. Ул Оренбург якларында тыныч кына хезмәт иткәндә Бөек Ватан сугышы башлана. Кыска вакытлы хәрби өйрәнүләрдән соң өченче Украина фронтына җибәрелә һәм атлы кавалериягә билгеләнә. Бервакыт дошман көчләренә каршы тора алмыйча чигенгәндә ул яралана. Аны ут эченнән Истапчик кушаматлы аты алып чыга. Ат каты җәрәхәтләнгән була һәм гөрселдәп җиргә ава. «Күземнән яшь атылып чыкты, атымны кочаклап алдым, ул хушлашкандай кешнәп җибәрде», - дип сөйли әнием бабайның сөйләгәнен искә төшереп.

Госпитальдә дәваланганнан соң ул пехотага билгеләнә. 1944нче елның 23нче апреле аның күңелендә онытылмас хатирә итеп уелган. Алар ротасына Тираспольгә бара торган юлны саклау бурычы йөкләнә. Автомат һәм кул гранаталары белән коралланган сугышчылар юл буйлап килүче немец танкларын күреп ала. Бу бәрелешүдә безнең герой сугышчылар 25 дошман танкын юк итә. Анда күрсәткән батырлыгы өчен бабаем Кызыл Йолдыз орденына лаек була.

Шәһәрләрне басып алганда никадәр төнге разведкаларда булырга туры килә аңа! Сугыш елларында 7 операция кичерә, сул күзен югалта. Ул соңгы тапкыр сугыш бетәргә биш көн кала яралана һәм 15 майга кадәр Кавказдагы госпитальдә ята.

Мәҗит бабай 2 орден, 11 медальгә лаек була. Шул исәптә, «Җиңү ордены», «Германияне җиңгән өчен» һәм «Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәте өчен» медальләре белән бүләкләнгән, күп кенә юбилей бүләкләре, алар арасында «Георгий Жуков» медале дә бар.

Икенче группа сугыш инвалиды булып кайткан бабайны колхозчылар яңадан бригадир итеп сайлый. 50нче елларда ферма мөдире булып эшли, әмма аны атлы эш сагындыра. Аннары фермада хисапчы һәм бер үк вакытта авылдагы май заводында ат белән сөт ташучы вазифаларын үти. Ләкин атларны ярату үзенекен итә. Ул 73 яшенә кадәр җәйләрен көтүче, кышын терлекче булып эшли. Лаеклы ялга киткәндә, колхоз рәисе аңа бүләк итеп атын бирә. «Ат җене» кагылган бабайга аннан да зур шатлык булмагандыр.

Бабам дәһшәтле сугыш елларын искә алганда «...сугышта алган яралар без күргән мәхшәрне искә төшереп тора. Без күрдек, сез күрмәгез», - дип тәмамлый иде, дип сөйли әни.

Карт бабай белән әби 53 ел бергә гомер кичергән. Алты бала үстереп, барысын да кеше иткәннәр. Бүгенге көндә 14 оныгы һәм 24 оныкчыгы үсә.

Ул 16 ел элек (6.01.2004) 85 яшендә якты дөньядан киткән. Бабаебыз исән булса, быел 100 яшь тулган булыр иде.

Тиздән җәй болын-кырларга ямь-яшел юрганын җәяр, ләкин атын болынга төшереп бәйләргә, көтү кайтканын көтеп, ишегалдына чыгып утырырга бабаебыз юк инде. Бабай белән бергәләп печәнгә йөргәнне, ат арбасына бер көтү оныклар утырып җырлый-җырлый җиләккә, мәтрүшкәгә барган бәхетле мизгелләрне моңсуланып сагынырга гына калды, дип сөйли әнием.

«Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!» – ди татар әйтеме. Гомер уза тора, киләчәк буын өчен Бөек Ватан сугышы ерак тарихыбызга әверелә бара. Быел Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итәбез. Сугыш беткәнгә дистәләгән еллар узса да, аның яралары өлкән буын күңелендә саклана. Ветераннарыбыз елдан-ел кими. Аларның батырлыкларын 9нчы Майда гына искә төшереп калмасак иде, мөмкин кадәр ешрак җиңүчеләребезгә хөрмәт, игътибар күрсәтик һәм яратуыбызны ешрак белдерик! Алар моңа һичшиксез лаек!

**Салават ВАСИЛОВ, 7 «Г»**



# ИЖАТ ДУЛКЫНЫНДА

## МИНЕМ БАБАМ – ФРОНТОВИК!

Бабайлар көрәшеп безгә
Тынычлык яулап алган.
Ә күпләре кайталмыйча,
Сугыш кырында калган.
Тиздән Җиңү бәйрәме,
Бәйрәм итәр бар халык.
Кайберләре сагышланып,
Кайберләре шатланып.
Әби сөйли, бабаемның
Яу кырында булганын.
Һәр ел саен бу бәйрәмне,
Елап каршы алганын.
Күкләребез аяз булсын,
Сугыш уты янмасын.
Әби-бабайлар язмышын

**Рүзәл ГЫЙНИЯТУЛЛИН, 7 «А»**



*9 «В» сыйныф укучысы* ***ВОЛКОВА Дарьяның*** *рәсеме*



## ҖӘЛИЛ ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНДА УЙЛАНУ

Җәлил һәйкәле янында
Булдым мин әни белән.
Хәзер аның батырлыгын
Мин инде яхшы беләм.
Кул-аяклар богауланган,
Горур басып тора ул.
Фашист куркыта алмаган,
Аңа буйсынмаган ул.
Көрәштәшләре турында
Сөйләде миңа әни.
Шундый батыр абыйларны,
Белмәгәнмен икән мин.
Хәзер Җәлил шигырьләрен
Без укыйбыз бергәләп.
Мәктәпкә дә йоклап калмыйм,
Сәгатьне гаепләмим.
Иптәшләремә дә сөйлим
Җәлил, синең турында.
Муса абый, сиңа килдем,
Ал чәчәкләр кулымда.
Синең алда хөрмәт белән,
Башыбызны иябез.
«Рәхмәт сиңа, Шагыйрь абый,
Онытмабыз!» - диябез.

**Хәсән ЛОТФУЛЛИН, 5 «Б»**

## СУГЫШ КАБАТЛАНМАСЫН!

Сугыш килеп алып китте
Кемдер исән, кемдер үлеп калды.
Исәннәрнең хәтерендә сугыш,
Үлгәннәрнең баш очында
Йолдыз булып янды.
Яшь кызлар да курыкмыйча
Яуга кергән мылтык асып.
Бик күпләре чит-ят җирдә
Иле өчен ятып калды
Кайтканнары инде бүген бик карт әби-бабай,
Күзләреннән яшьләр тама.
Армиягә киткән оныкчыгын
Сагынып көтеп ала.
Авыр еллар егетләрне
Сугышка алып китмәсен.
Мәрхәмәтле җаннарны да
Яманга ул илтмәсен.
Дөньялар тыныч торсын,
Сугыш кабатланмасын!
Безнең өчен әниләрнең
Күз яшьләре таммасын!

**Алинә МӨБӘРӘКШИНА, 8 «Л»**




*1 «И» сыйныф укучысы* ***ХРАМЦОВА Маринаның*** *рәсеме*

ШКОЛА РАДОСТИ
**Главный редактор:** Файзуллина Л.Ф.
**Зам. редактора:** Шакирова И.
**Редколлегия:** Мусаяпова Н.Х, учителя родного татарского языка
Тираж 100 экз.
**Адрес редакции:** 420037, РТ, Казань, ул. Симонова, д. 17, ПРЕСС-ЦЕНТР
**Телефон редакции:** 8 (917) 247-60-30
**E-mail:** lyaisan1985@mail.ru

БЕЗ БУЛДЫРАБЫЗ! МЫ МОЖЕМ! YES, WE CAN!